РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
КУКМОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
СОВЕТ ЯДЫГЕРЬСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
422124, РТ, Кукморский район,
с. Ядыгерь, ул.Ленина д.28а

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯДЕГӘР АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
422124, РТ, Кукмара районы,
Ядегәр авылы, Ленин урамы, 28а йорт

тел.: (8 84364) 35-5-88, факс (8 84364) 35-5-88; e-mail:Yad.Kuk@tatar.ru

# КАРАР

07 ноябрь 2024 ел №7

«Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл җирлегенең Тарлау авылы торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1.2024 елның 21 ноябренә 18 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл җирлегенең Тарлау авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Тарлау авылы, Г.Ибраһим урамы, 11 нче “а”йорт адресы буенча урнашкан мәчет бинасында үткәрергә.

2.2024 елның 26 ноябренә 18 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл җирлегенең Тарлау авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын үткәрүне билгеләргә Гражданнар җыенын Тарлау авылы, Г.Ибраһим урамы, 11 нче “а”йорт адресы буенча урнашкан мәчет бинасында үткәрергә.

3.Гражданнар җыенын үткәрү өчен торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча (урамнар буенча) бүләргә.

4.Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:«1 төркем инвалидлар, көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлар (курсантлар), 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз әниләр, 80 яшькә җиткәннәр һәм аннан да өлкәнрәкләр, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлар, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзалары, махсус хәрби операциядә катнашучы хәрби хезмәткәрләр һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл җирлегенең Тарлау авылы

территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2025 елда үзара салымны 500 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (Тарлау авылындагы юлларны кышкы-җәйге тоту һәм проект-смета документациясен эшләү, килешү буенча түләү);

(Пушкин урамы, Тарлау авылы буенча вак таш белән капланган юллар төзү һәм ремонтлау, проект-смета документациясен эшләү һәм технадзорны гамәлгә ашыру, килешү буенча түләү);

(Тарлау авылы урамнарына асфальт салу, проект-смета документациясен эшләү, технадзорны гамәлгә ашыру һәм экспертиза үткәрү, килешү буенча түләү);

- тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны (энергия саклаучы лампаларны, светодиодлы яктырткычларны, Тарлау авылында махсус җиһазларны сатып алу, урнаштыру, ремонтлау һәм тоту)ремонтлау;

- җир асты суларының табигый чыгу урыннарын төзекләндерү (чишмәләр) (төзекләндерү, чишмәләрне тоту, проект-смета документациясе, технадзорны гамәлгә ашыру, материал сатып алу, ташу һәм чишмәләрне төзекләндерү һәм тоту буенча башка эш төрләре);

- су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (су күтәрү манарасы өчен насос сатып алу һәм урнаштыру, су белән тәэмин итү трассасын төзү һәм ремонтлау проект-смета документациясен эшләү, килешү буенча түләү);

- торак пункт территориясен төзекләндерү ("Сабантуй" уздыру урыннарын төзекләндерү, проект-смета документларын эшләү, килешү буенча түләү);

(Тарлау авылы мәчете каршында парковка урыны төзү, проект-смета документациясен эшләү, технадзорны гамәлгә ашыру һәм экспертиза үткәрү, килешү буенча түләү);

(халыкның күпләп ял итү урыннарын төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү, проект-смета документациясен эшләү, килешү буенча түләү);

- традицион Күмү урыннарын ремонтлау, коймалар төзү, төзекләндерү (Тарлау авылындагы зиратларны саклау, материаллар, кораллар сатып алу һәм коймаларны урнаштыру, проект-смета документациясен эшләү һәм технадзорны гамәлгә ашыру, килешү буенча түләү);

«РИЗА» «КАРШЫ»

5. Җыенны оештыручы итеп Ядегәр авылы башкарма комитетын билгеләргә.

6.Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Ядегәр авыл җирлеге башлыгы: А.Н.Фәйзуллин